**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Зирекле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

«18» ноябрь 2022 ел № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 18 ноябрендә узган: «Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

торак пункт чикләрендә авыл эчендәге җирле әһәмияткә ия юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 213 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 119 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 119 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Зирекле авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Биляр-Озеро авыл җирлеге Зирекле авылы территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, көндезге формада белем алучы студентлардан кала, 2023 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

торак пункт чикләрендә авыл эчендәге җирле әһәмияткә ия юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

су белән тәэмин итү чыганакларына норматив таләпләрне тәэмин итү буенча эшләр үткәрү;

урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биляр-Озеро авыл җирлегенең Зирекле авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: В.С.Оренбургов

Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы: В.С.Оренбургов